# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар» (Коръән Кәрим. 2-256)

اسلام نورى

12+

№ 16 (668) 20 август 2018 ел (1439, Зөлхиҗҗә) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


## Корбан гаете мөбарәк булсын!



Әссәламугаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү!

Мөхтәрәм дин кардәшләрем!

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән сезне Корбан бәйрәме белән тәбриклим! Аллаһы Тәгалә барлык изге гамәлләребезне кабул итсен. Гыйбадәтләребезгә савапны арттырып биреп, ике дөньяда да Үзенең иксез-чиксез рәхмәте белән бүләкләсә иде! Әлеге мөбарәк бәйрәмебез һәрбер йортка шатлык, иминлек, муллык һәм Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен алып килсен!

Корбан бәйрәме – бөек бәйрәм. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: “Аллаһы Тәгалә каршында иң яхшы көн – Корбан бәйрәменең беренче көне”. Корбан бәйрәменең тарихы Ибраһим пәйгамбәр вакыйгасы белән турыдан-туры бәйле, ул Аллаһы Тәгаләнең әмеренә буйсынып, үзенең күптән көтеп алынган улын корбан итәргә әзер була. Әмма Бөек Зат – Рәхимле һәм Гадел. Ибраһим галәйһиссәламнең итагатьле булуына инанган хәлдә, Ул: “Хакыйкатьтә, бу – ачыктан-ачык сынау! Син аны уңышлы уздың”, – дип әйтә. Шуннан Раббыбыз Ибраһим галәйһиссәламнең улын корбан итү урынына корбанлык малын кабул итеп ала һәм тагын бер баланың дөньяга килүе белән бүләкли. Моның белән Аллаһы Тәгалә шуны күрсәтә: Аллаһыга якын булу өчен, кешенең корбан булуы таләп ителми, әмма Аллаһының кушканнарын берсүзсез үтәү һәм хакыйкать юлында үз-үзеңне аямыйча хезмәт итү сорала. Башка сүзләр белән әйткәндә, ел саен корбан чалу – Аллаһы ризалыгы өчен үзеңнең барлык мал-мөлкәтеңне мохтаҗлыкка төшкәннәргә корбан итәргә риза булуыңны күрсәәү ул.

Корбан бәйрәме көннәрендә корбан чалу, аның барлык таләпләрен үтәү бик мөһим. Менә шуның өчен дә Гыйд әл-әдха бәйрәме дәвамында зирәк һәм юмарт кеше әйләнә-тирәдәгеләргә шатлык, игелек һәм бәхет алып килергә, сәдака бирергә, мохтаҗларга корбан итен тапшырырга, ә иң мөһиме – Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алырга һәм рухи яктан канәгатьләнү хисенә омтылырга тиеш. Шулай итеп, корбан чалу гамәле кешеләр арасында бердәмлек һәм дуслык ныгуга ярдәм итә.

Әлеге көндә Аллаһы Тәгалә безгә рухи шатлык һәм Аның рәхмәте чагылышын тою өчен ихластан гыйбадәт кылырга насыйп итсә иде. Раббыбыздан безнең корбаннарыбызны, хаҗиларыбызның хаҗларын кабул итүен һәм барысының да туган җирләренә исән-сау әйләнеп кайтуларын телим! Аллаһы Тәгаләдән Үзенең рәхмәтеннән аермавын, бәхет һәм сәламәтлек, ә илебезгә һәм республикабызга иминлек, татулык, бердәмлек, бәрәкәт сорыйм!

Бәйрәм белән, хөрмәтле мөселман кардәшләребез!

**Камил хәзрәт Сәмигуллин,**
**Татарстан Республикасы мөфтие.**

## Рәхимле, Мәрхәмәтле Аллаһ исеме белән!



Мөхтәрәм дин кардәшләр!

Сезне, гаилә әгъзаларыгызны, туганнарыгызны ҮДО – Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Чаллы мөхтәсибәте һәм үз исемемнән мөбарәк Корбан бәйрәмебез белән чын күңелдән тәбрик итәм!

Корбан бәйрәме – Исламның бишенче баганасы булган олуг хаҗның тәмамлану вакыты. Бу көнне изге Мәккә җирендә миллионлаган хаҗилар, шул исәптән шәһәрдәшләребез, җирдә тынычлык, иминлек, шәһәребездә бәрәкәт булсын өчен догалар кылалар. Аларның хаҗлары кабул булып, үзләренең исән-сау әйләнеп кайтуын телибез.

Корбан бәйрәме Ураза бәйрәме кебек үк социаль әһәмияткә ия. Ошбу бәйрәмдә без мохтаҗ кардәшләребезгә корбан итләре өләшәбез, сәдакаларыбызны бирәбез, аларны шатландырабыз, шул рәвешчә җәмгыятебезне тотрыкландыруга өлеш кертәбез. Корбан чалу мәзһәбебез буенча нисабы җиткән кешеләргә вәҗиб, ягъни тиешле гамәл. Аллаһы Тәгалә әйтә: “Без сезгә терлекләрне корбан итүне йола итеп билгеләдек. Анда сезнең өчен зур файда бар” (22:36). Аллаһы Тәгаләгә чалган корбаннарыбызның ите дә, каны да кирәк түгел. Ул фәкать ошбу гыйбадәт белән тәкъвалыгыбызны, үзебезгә бирелгән нигъмәтләргә шөкер итә белү-белмәвебезне сыный.

Корбан чалу бәйрәмнең өч көнендә дә башкарыла. Өченче көннең ахшам намазыннан соң аны чалу ярамый. Корбанга чалынучы сарык, кәҗә 1 яшьтән, сыер исә ике яшьтән ким булмаска тиеш. Корбанлык өчен физик яктан сәламәт һәм көр булган мал гына сайлап алына. Сыер малын 7 кеше исеменнән чалырга мөмкин. Бер кеше исеменнән генә чалынса да дөрес. Корбан ите гадәттә өчкә бүленә. Аларның бер өлеше фәкыйрь-мескеннәргә, ятимнәргә, балалар йортларына, мәдрәсәләргә, икенче өлеше туганнарга, күршеләргә өләшенә. Ә өченче өлешен хуҗа үз гаиләсе өчен калдыра. Үзе хәлле булып тулаем мохтаҗларга бирсә, әҗере күбрәк була. Мохтаҗ гаилә корбан чалып, аны тулысынча үзе өчен тотса да дөрес була.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте казыяты быел Корбан нисабы күләмен 18500 сум дип билгеләде. Гаиләдә Аллаһы Тәгалә чалган корбаннарыбызны һәм Үз ризалыгы өчен кылган барча изгелекләребезне кабул итеп, алар өчен әҗер-савапларны арттырып бирсә иде!

Бәйрәмебез мөбарәк булсын!

**Әлфәс хәзрәт Гайфуллин,**
**ҮДО - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте**
**Президиумы әгъзасы, Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе.**

## Имамнар җыелышы



Актанышның Җәмигъ мәчетендә имамнарның чираттагы җыелышы узды. Җыелышта район имам-мөхтәсибе Руслан хәзрәт Мортазин үткән эшләргә нәтиҗә ясап, алда торган бурыч-максатлар белән таныштырды. Шулай ук имамнар көнүзәк мәсьәләләрне хәл иттеләр, алга планнар билгеләделәр. Җыелышта Корбан бәйрәме хакында да сораулар бирелеп, аларга җаваплар алынды.

Чара ахырында барлык имамнарга да “Шура” журналының 21 нче саны таратылды. Имамнар җыелышы киләсе айларда да үтәчәк.

## Яңа мәчет



Кама Тамагы районы Куйбышев исемендәге Затонда мәчет ачылу тантанасы узды. Әлеге чарада Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин, Кама Тамагы районы башлыгы Павел Лоханов, аның урынбасары Газинур Габидуллин, район имам-мөхтәсибе Галимулла хәзрәт Яруллин, имамнар, иганәчеләр һәм авыл халкы катнашты.

Куйбышев исемендәге Затон поселогында мәчеткә беренче таш 2016 елда салына һәм тагын бер елдан Юстиция министрлыгында теркәлү уза. Мәчет түбә астына керү белән үк, дин кардәшләребез мәчеттә җомга намазларын укыйлар. Поселокта мәчет ачылу мөселман кардәшләребез өчен зур бүләк булды.

Татарстан мөфтие урынбасары мәчетнең функцияләре һәм мәчетнең эшләү тәртибе турында сөйләде. Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин мәчет төзелешенә зур өлеш кертүчеләргә рәхмәт хатлары тапшырды.

Район башлыгы мәчет төзелешенең күркәм эш булуын ассызыклады.

Кама Тамагы районында бүген 28 мәчет эшли.

# Кичектерү

***Бервакыт әл-Аъша бнү Мәймүн исемле бер шагыйрь Аллаһның илчесен (с.г.в.) мактый торган шигырьләре белән Мәккә шәһәренә юнәлә. Корайшит кәферләре моны белеп алгач, бу шагыйрьнең матур сүзләре кешеләрнең йөрәкләренә үтеп керер, аларның ислам динен кабул итүләренә сәбәпче булыр дип куркып, аны туктатырга һәм шагыйрьгә комачау итәргә карар итәләр. Әбү Суфьян аның белән очрашып, Пәйгамбәребез (с.г.в.)не истә тотып, болай ди: “Ә син аның нинди эшләрне тыюын беләсеңме?” Әл-Аъша бнү Мәймүн кызыксынып: “Нинди?” – дип сорый. “Ул зина кылуны, комарлы (ягъни отышлы) уеннарны, исерткеч эчемлекләр эчүне тыя”, – ди Әбү Суфьян. Моны белеп алгач, әл-Аъша бнү Мәймүн ислам динен кабул итүдән баш тарта. Корайшитлар моның өчен аңа 100 дөя бүләк итәләр. Ул дөяләрен алгач: “Бу елны мин үз рәхәтемә яшим, ә киләсе елда ислам динен кабул итәм”, – дип үз кавеменә кайтып китә. Әмма өенә кайтып җитә алмыйча, юлда дөя өстеннән егылып төшеп үлә.***

Йә, Аллаһның коллары! Кеше тормышында кичектерүдән дә куркынычрак чир бар микән? Соңрак эшлим, өлгерәм әле дип адашулар бик куркыныч нәрсә.

Әйе, Аллаһы Тәгаләгә булган гамәл-гыйбадәтләреңне кичектерү бик куркыныч нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Киресенчә, ашыктыру, вакытында эшләү уңышка, бик яхшы нәтиҗәләргә китерә. Кичектерү кешенең иң явыз дошманнарының берседер. Бу дошман аның тормышын харап итә. Кеше кадерле тормышын, мизгелләрен бер файдасыз, бушка үткәрә. Белегез, кичектерү бу дөньяда бернинди уңышка ирешмәүнең иң беренче, зур сәбәпләрнең берседер.

И кадерле дин кардәшләрем! Кеше кичектерү тозагына төрле сәбәпләр аша эләгә. Һәм шуларның иң төп сәбәбе – уңышсызлыкка ирешүдән курку. Теләкнең җиңел булуы, тәвәккәллек булмау, җиңеллек һәм комфортны гына сайлау, буш хыяллар, бу дөньяның кыска гына аралык икәненә һәм аның тиз бетәчәгенә гамьсез булу. Аллаһы Тәгалә Үзенең Коръәни-Кәрим китабында әйткәнчә, үлемнең кинәт, көтмәгәндә килүен оныту.

Йә, газиз дин кардәшләрем! Иң зур һәм иң куркыныч кичектерү – ул кешенең Раббысы белән мөгамәләсен кичектерүе, Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәүне кичектерүе. Вакытлар үтү белән бу гамәл-гыйбадәтләрне эшлисе килү теләге дә суына, Аллаһы Тәгаләгә омтылышларың көннән-көн көчсезләнә, ахыр чиктә, кеше гомумән аны калдыра.

Аллаһның колы намазга басарга теләсә, шайтан аны намазның вакытын кичектерергә котырта башлый. Намазның вакыты чыкканчы шулай котыртып, бу кешене Раббысы белән арасы өзелгәнче калдырмый.

Йә, иман китергән Аллаһның коллары, Аллаһның китабында бик күп аятьләр изге гамәлләрне кичектерми эшләргә чакыра. Аллаһы Тәгалә әйтә:

“Раббыгызның кичерүенә һәм киңлеге күкләр һәм җирнеке кадәр булган, тәкъва кешеләргә әзерләнгән Җәннәткә ашыгыгыз” .

Шулай ук Аллаһы Тәгалә әйтә: “Раббыгызның кичерүенә һәм киңлеге күк һәм җир киңлеге кадәр булган Җәннәткә ашыгыгыз”.

Аллаһның китабын игътибар белән укыган кеше бик күп аятьләрдә Аллаһы Тәгаләнең кичектерүдән кисәтүен күрер. Эшне бер генә көнгә кичектерсәң дә, үкенүдән файда булмаячагы искәртелә. Аллаһы Тәгалә әйтә: “Аларның берәрсенә үлем килсә, ул: “Раббым! Мине дөньяга кире кайтар. Шаять, мин кылмаган изге гамәлләрне кылырмын”, – дияр. Юк! Әлбәттә, ул бары тик бер сүздер”.

Бөек Аллаһы Тәгалә әйтә: «Без сезгә биргән малдан мохтаҗларга һәм Аллаһ юлына сездән берегезгә үлем килгәнче сәдака бирегез. Үлем килгәч, ул кеше әйтер: «Йә Раббым! Минем үлемне аз гына вакытка кичектерсәңче, сәдакалар бирер идем һәм башка изгелекләрне эшләп, яхшы кешеләрдән булыр идем”, - дияр”.

Ибн Кәсир әйтте: «Аллаһы Тәгалә әйтә: «Алар бу дөньяга кире кайтаруны сорарлар, әмма аларга ни үлгән вакытларында, ни кире терелтелгәч, ни Раббылары каршына җавап тотарга баскач, ни утка атканда беркем җавап бирмәс. Алар Җәһәннәм утында булырлар».

Пәйгамбәребез (с.г.в.) сөннәтенә килгәндә, ул шулай ук кешеләрне кичектерү чиреннән кисәтә. Мөмкинлекләр кулдан киткәнче, башка эшләр игътибарны читкә этәргәнче, кичектермичә, Аллаһы Тәгаләгә буйсыныгыз, ди ул.

Аллаһның Илчесе (с.г.в.) әйтте: «Изге гамәлләр кылырга ашыгыгыз, чөнки һичшиксез караңгы төнгә охшаган сынау вакытлары җитәр. Ул вакытта иртән иманлы кеше кич инде кәфер булыр һәм кичен әле иманлы булган кеше иртәнгә үзенең динен дөнья малына саткан кәфер булыр».

Шулай ук Аллаһның Илчесе (с.г.в.) әйтте: «Алты нәрсә килгәнче изге гамәлләр кылырга ашыгыгыз: кояш көнбатыштан чыкканчы, төтен, дәҗҗал, җирдән җанвар чыкканчы, шәхсән һәркемгә кагыла торган үлем килгәнче һәм гомум афәт килеп җиткәнче».

Йә, иман китергән Аллаһның коллары, карагыз! Аллаһы Тәгалә һәм Пәйгамбәребез (с.г.в.)нән күпме кисәтү һәм үгетләүләр килгән! Ни өченме? Без Раббыбызга тагын да якынаерга омтылсыннар өчен. Әмма шуңа да карамастан, без әле һаман ваемсыз, ихтыярсыз булып калабыз. Без бары тик хыялланырга һәм кичектерергә оста. Әле тормыш алда, яшиселәр бар әле, өлгерермен дип, үзебезне тынычландырып, бу дөнья белән алданабыз. Шулай итеп, кеше тәүбәсен һаман калдыра, суза, һәм киләсе тормыш уңышларына, ахирәт тормышына көннән-көн ваемсызрак карый башлый. Бигрәк тә 70-80 яшьлек әби-бабайларның ахирәттән гамьсез, киләсе тормышка, Раббыларына ваемсыз мөнәсәбәтләрен күреп гаҗәпләнәсең... Әйтерсең алар мәңгелек яшәргә килгәннәр.

Бер шигырьдә мондый юллар бар: “Әгәр иген чәчеп тә, аны карамасаң, игътибарсызлыгың өчен соңыннан үкенерсең.”

Шулай ук кичектерүнең бер төренә бер кешенең икенчесенә гаделсезлек кылуы керә. Изгелеккә омтылучыларның Раббысы ни ди, карагыз: «Кем дә кем берәр кешене рәнҗетеп, аңа гаделсезлек яки башка нәрсә кыла икән, аннан бүген, ягъни динар белән дирхәмнәр юкка чыга торган вакыт җиткәнче гафу үтенсен». Ягъни Кыямәт вакыты килеп җиткәнче тизлек белән гафу үтенсен.

Галимнәр әйтәләр, инде бер кешенең хокукына кердең икән, тәүбә итсәң дә, хәтта Аллаһ юлында вафат булып китсәң дә, колларның (кешеләрнең) хокуклары әле синнән төшми. Имам Нәвәви әйтте: “Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең “әҗәтеннән баш-ка” дигән сүзләре кешенең барча хокукына кагылуны аңлата, ди. Ни җиһат кылу, ни Аллаһ юлында вафат булу һәм башка төрле изге гамәлләр кылу кемдер алдында әҗәтең булуны өстеннән төшерми.

Йә, Аллаһның коллары! Карагыз, кичектерү нинди куркыныч нәтиҗәләргә китерә: гөнаһлар артканнан-арта бара, хәтта зур-зур таулар кебек өелә, һәм кеше үлем, көферлек упкыны читендә яши башлый, ашаган ризыгының тәмен тоймый, уңышлары аны шатландырмый. Һәм бервакыт шундый көн җитәр, аның үкенече үзенә бернинди файда китермәс.

Карагыз, бу чир инде бу дөньяда нинди яман нәтиҗәләргә китерә. Йөкләнелгән эшләрен калдырып килү, һаман саен кичектерүен аңлап, кешеләр аның сүзләренә ышанудан, эшләрендә булышудан туктарлар. Чөнки аның сүзләре гамәл белән расланмаган буш сүзләр. Һәм кешенең үзенең дә күңеле төшәр. Тәүбәне кичектерүнең нәтиҗәләре дә һәлакәткә китерә. Кеше үзенең теләкләренә бирешә башлый, шайтан аны озын гомер белән, тәүбә итәргә өлгерерсең әле дип алдалый. Һәм бу кеше тормышында иң зур югалту. Бу Җәннәткә керүне югалту.

Ибн Кайим кичектерүдән кисәтеп болай дигән: «Гөнаһ кылганнан соң кичектермичә тәүбә итү һәркемнең бурычы. Бу эштә беркайчан кичектерергә ярамый. Кем кичектерә, шул моның белән гөнаһ кыла. Шуңа күрә гөнаһыннан тәүбә иткән кешегә тәүбәсен кичектергәне өчен дә тәүбә итәргә кирәк. Һәм бик аз кеше моның турында уйлана. Гөнаһымнан тәүбә итсәм, шул җитә, бернинди гөнаһым калмый дип уйлыйлар алар. Ә чынлыкта аңа әле кичектергәне өчен дә тәүбә итәргә кирәк. Моннан бары тик белеп һәм белми кылган гөнаһлардан тәүбә итү генә коткара ала».

И газиз дин кардәшләрем, Аллаһтан куркыгыз! Күбрәк изге гамәлләр кылырга ашыгыгыз! Безнең тормышыбыз минутлардан, секундлардан тора. Кичектерүчеләргә хәтта бу дөнья тормышының капкалары да ачмас, ә киресенчә, эш-гамәлләрен вакытында эшләүчеләр өчен ачылыр.

Бүгенге сүзләрем белән вакытның кыскалыгын исегезгә төшереп, мин үзем өчен дә, сезнең өчен дә Аллаһтан ярлыкауны сорыйм. Сез дә ярлыкавын сорагыз, һәм Ул җавап бирер, Аллаһы Тәгалә Кичерүче, Ярлыкаучы, Рәхимле.

Кичектерү яман чиреннән вакытның кыска икәнен, тормышның кыска гына вакытка бирелүен искә төшерү һәм кайчан үләсеңне белмәү – иң яхшы дәва. Уңыш бары тик ахирәттә. Уңышка бары тик эшләрне, бирелгән мөмкинлекләрне файдаланып, вакытында эшләгәндә генә ирешеп була. Тырыш кешеләр белән аралаш. Зур-зур галимнәребез бик тырыш булганнар, аларның тормышларын өйрән, алардан үрнәк ал. Алар бит тырышлыклары, эш-гамәлләрен вакытында эшләү белән уңышка ирешкәннәр.

Гомәр бнү Хаттабтан җиткерелә: “Синең көчле икәнеңне гамәлләреңне иртәгәгә калдырмавың, кичектермәвең күрсәтә”.

Йә, газиз дин кардәшем! Үзеңнең җаның белән катгый бул, аны һәрдаим тикшереп тор, хисап тот. Кыю бул. Җаныңны тәүбә итеп чистарт, Раббыңа кайт. И кадерле туганым, мин сине кичектерүдән саклаunion чакырам, кичектерү чиреннән кисәтәм.

Йә Раббыбыз Аллаһ! Без Сиңа ваемсызлыктан, гамьсезлектән, буш өметләрдән сыгынабыз! Йә әр-Рахман, йә әр-Рәхим, аннан безне сакла! Әмиин!

**Әбүбәкер хәзрәт Әбдиев,**
**Чаллының “Тәүбә” мәчете имам-хатыйбы.**

## БЕЛӘСЕЗМЕ?

*Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә игътибар бирмичә, нинди кешеләр белән бөтенләй сөйләшмичә, аларга җәза бирер?*

*1. Гыйлемне яшерә торган галимнәр. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: "Әгәр кеше дин гыйлемен үзләштерү максаты белән башка белә торган кешедән нәрсә дә булса сораса, һәм теге кеше җавап бирмәсә, шул җавап бирмәүче (Кыямәттә) ут белән йөгәнләнәр.*

*2. Үз әйберләренең кимчелекләрен күрсәтмичә, яшереп, алдап сатучы.*

*3. Олы яшьтәге зина кылучы.*

*4. Алдакчы патша (үз халкын алдый торган хаким).*

*5. Тәкәббер фәкыйрь.*

*6. Ата-анасын рәнҗетүче ( ата-ана хакын үтәмәүче).*

*7. Ирләргә охшарга тырышкан хатын.*

*8. Хатынының теләсә ничек йөрүенә риза булып торучы ир (хатынына һәм гаиләсенә карата җавапсыз булган ир).*

*9. Үз хатынына карата җенси азгынлык кылучы ("Әл-Бәкара/ Сыер", 2:222)*

*10. Үз киемнәрен тәкәбберлек белән, мактанып киеп йөрүче.*

*Безгә язалар*

# Корбан чалу үзенчәлекләре

Корбан чалу – моны башкарырга мөмкинлеге булган һәрбер мөселманның Аллаһ каршындагы бурычы. Әгәр кешенең матди хәле корбан сатып алырлык булмаса, аңа корбан чалу мәҗбүри түгел. Зәкәт бирү, ураза тоту кебек, корбан чалу да кеше өстендә булган, ел саен башкарыла торган гамәлдер. Әйтик, бер мөселман "былтыр үзем өчен ураза тоттым, быел әби өчен тотам" дип ниятли алмаган шикелле, корбан чалуны да ел саен үзе исеменнән башкарырга тиеш. Әмма бездә кайберәүләр: "Өченче ел үзем өчен чалган идем, былтыр – хатын, ә быел исә малай исеменнән чалам", – дип белдерә. Әлбәттә, бу дөрес түгел. Гаиләдә фәкать бер генә сарык Корбан итәргә мөмкинлек бар икән, ул гаилә башлыгы исеменнән чалынсын (алай эшләнсә, барлык гаилә әһелләренә дә савап була, иншә Аллаһ). Башка гаилә әгъзасы яки вафат булган туганың исеменнән дә корбан чалырга ярый, ләкин әүвәл гаиләдәге ир кеше (хуҗа) исеменнән чаласы, ә туганнарың өчен икенчене чалу таләп ителә.

Кайберәүләр Корбан гаете көннәрендә нәзер корбаны чала. Әмма гаетнең 3 көне дәвамында вәҗеб булган корбан гына чалына, ә нәзер корбанын башка көннәрдә чалырга кирәк. Нәзер корбанын аны чалган иясенә ашарга ярамый (аны тулысынча тараталар), ә вәҗеб корбанның итен, гәдәттә, өчкә бүләләр: бер өлешен үз гаиләңә калдырырга була, икенчесен – мохтаҗларга бирергә, өченчесен исә йә күрше-күләнгә күчтәнәч итеп өләшәләр, йә мәҗлес җыеп кунакларны сыйлыйлар.

Гакыйка, ягъни бала туу хөрмәтенә чалына торган корбанны да Корбан гаете көнне чалынырга тиешле вәҗеб корбан белән бутарга ярамый. Гакыйканы гает көнендә чалырга мөмкин, әмма шулай ук – вәҗеб корбаннан соң икенчесе итеп. Андый мөмкинлек юк икән, гакыйканы башка вакытка күчерергә кирәк.

Корбанның нинди төре булса да, аны фәкать Аллаһ ризалыгы өчен дип чалырга тиешле. Кайберәүләр "эшләрем җайлансын, хәлем җиңеләйсен" дип корбан чала. Әмма бәрәкәт, уңыш, сәламәтлек һәм башка нигъмәтләр Аллаһ ризалыгы эчендә бар. Безнең ике дөнья бәхете дә Аллаһ ризалыгы белән бәйле. Корбан чалу исә Раббыбыз разый булган иң зур гамәлләрнең берсе. Галимнәр аңлатканча, корбанның беренче кан тамчысы җиргә төшү белән, корбан чалучының гөнаһлары ярлыкана, корбанлык тиресендәге йон төкләре санынча савап языла... Шушы мәгълүматны һәм пәйгамбәребезнең: "Кем дә булса, мөмкинлеге булып та, корбан чалмый икән, гаеттә безнең мәчеткә якынлашмасын" дигән хәдисен игътибарга алсак, әлеге гамәлнең нинди зур әһәмияткә ия булуы аңлашылыр.

**Ришат хәзрәт Курамшин,**
**Кукмара мәдрәсәсе мөдире.**

# *Мәрхәмәтлелек*

*Дога белмим дисең нигә?*
*Яхшылык –үзе дога!*
*Бар кеше изгелек кылса,*
*Яктырыр иде дөнья.*
*Изгелек ул – беркайчан да*
*Тузмый торган хәзинә.*
*Яхшылык эшлик һәрвакыт,*
*Ул үзе изге дога!*

Аллаһ Сүбхәнә вә Тәгалә Бөек Коръән Кәримдә: «Яхшылык эшләргә ашыгыгыз», ди. Кеше гомере буена мөмкин кадәр күбрәк изгелекләр эшләргә тиеш, алар барысы да исәпләнәләр һәм килер бер көн – яхшы эшләребезнең күп булуы безгә бик-бик кирәк булачак. Аллаһы Тәгалә Фуссыйләт сүрәсендә әйтә: «Кем дә кем яхшылык эшләсә, моның файдасы аның үзенә була, ә кем дә кем начарлык эшләсә, моның зарары үзенә булачак. Синең Раббың колларына әз генә дә гаделсезлек кылмый».

Мәрхәмәтлелек ул – тирә-юньдәгеләргә ихтирамлы һәм игътибарлы булу, бер-береңә ярдәм итү, игелекле эшләрне күбрәк эшләргә тырышу, олыларга һәм үзеннән кечерәкләргә ихтирамлы булу.

Бервакыт Пәйгамбәребез (с.г.в.) оныгы Хәсәнне кочаклап үпкәндә, аны Әкра ибне Хәбис исемле иптәше күрә һәм әйтә: "Димәк ки, сез балаларны үбәсез. Минем ун балам бар, минем аларны беркайчан да үпкәнем юк". Пәйгамбәребез ул кешегә исе китеп карап тора һәм җавап бирә: "Мәрхәмәт итмәгән кешенең үзенә дә мәрхәмәт кылынмас". Бу хәдистән чыгып нәрсә әйтә алабыз? – Олылар кечеләргә карата мәрхәмәтле булырга тиеш.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткән: "Кешеләргә карата мәрхәмәтсез булган кеше үзе дә Аллаһының мәрхәмәтеннән мәхрүм булачак".

Без кешеләргә генә түгел, табигатькә, үсемлекләргә һәм хайваннарга карата да мәрхәмәтлелек күрсәтергә тиешбез. Берзаман Пәйгамбәребез иптәшләренә җәһәннәмдә җәфа чигүче бер хатын турында сөйли. Бу хатын, мәчесенә ачуы чыгып, аны бер бүлмәгә япкан. Аңа ашарга да, эчәргә дә бирмәгән. Мәче үлгән. Мәчесенә каты күңеллелек күрсәткәне, мәрхәмәтсез булганы өчен хатын җәһәннәмгә эләккән.

Ә менә икенче бер риваятьтә башка мисал китерелә. Гарәбстанда, бик эссе бер җәй көнендә, бик бозык, әхлаксыз хатын кое яныннан үтеп барганда, сусызлыктан интеккән бер этне очрата. Аңа коедан су алып эчермәкче була, ләкин савыт тапмый. Озак уйламыйча, хатын коега төшә, һәм башмагына су җыеп эткә эчерә. Шулай бу эт үлемнән котыла. Бу гамәле өчен Аллаһ бу әхлаксыз хатынның барлык гөнаһларын да гафу итеп, аны җәннәтле итә. Әйе, мәрхәмәтлелек өчен Аллаһ Тәгалә кешеләргә чиксез бүләкләрен, ә мәрхәмәтсезлек өчен җәза вәгъдә иткән.

Яхшы сүз дә шәфкатьле эш кебек икән. Тиккә генә әби-бабаларыбыз «Яхшы сүз – җан азыгы» дип әйтмәгәннәр инде аны! Кылган яхшы эшләр күңелдә, йөрәктә кала һәм бер булса да әйләнеп кайтачаклар.

Нәтиҗә ясап әйтсәк, мәрхәмәтле булу өчен нәрсәләр эшләргә кирәк? – Кешеләргә игътибарлы булырга, аларга ярдәм кирәк түгел микән дип уйларга тиешбез. Мохтаҗларга ярдәм итәргә кирәк. Табигатькә, хайваннарга карата мәрхәмәтле булырга кирәк. Игелекле эшне һәркөнне, һәрвакытта да эшләп була.

Аллаһ Сүбхәнә вә Тәгалә Изге Коръән Кәримдә әйтә: «Кем дә кем тузан бөртеге кадәр генә изгелек кылса, ул күренәчәк. Кем дә кем тузан бөртеге кадәр генә начарлык кылса, ул күренәчәк». – Бу сүзләрне беркайчан да онытмыйк, чөнки һәрбер изгелегебез өчен дә, һәрбер яманлыгыбыз өчен дә Аллаһы Тәгалә каршысында җавап бирәчәкбез.

**Язманы "Хәзинә" клубы мөгаллимәсе**
**Айгөл Шияпова әзерләде.**

# Тәкъдир

*(Хикәя)*

– Фатих бабай, шул әтәчне генә чалып бир әле? – диде Мәгъҗүзә, капкадан керә-керешкә.

Бабай абзар тирәсендә кайнаша иде. Печәнгә барырга дип, чалгысын кайрап, карап куясы бар. Берәр атнадан печән өсте. Капка ягыннан килгән тавышка бабай башын күтәрде. Мәгъҗүзәне күрүгә, кул аркасын балтырына сөртеп, каршы китте.

– Әйдүк, исән-имин генәме, Мәгъҗүзә килен?! – дип исәнләште карт. Ешлады килен, бу юлысында әтәч күтәргән, дигән уйлар узды. Уйларын укыгандай, Мәгъҗүзә:

– Печәнгә төшкәнче, Галиәсгар белән Бәдерхәятне чакырып алмакчы идем, – диде.

– Э-әә, Галиәсгар белән Бәдерхәятне алайса, – диюдән артыкны әйтә алмады, дөньяның гаҗәеп хикмәтен сиксән ел яшәп тә аңлап бетерә алмаган карт. Акылындадыр Мәгъҗүзә, дип, уйларынннан арынырга тырышты ул.

Ә Мәгъҗүзәнең үз уйлары... Галиәсгар белән яшәсә, урам буйлап әтәч чалдырып йөрмәс иде дә бит. Нишлисең, язмышыңа язылганны күрмичә булырмы?!

Язмыш дигәннәре Галиәсгар белән Мәгъҗүзәне аулак өйдә очраштырды. Мәгъҗүзә авыл матуры булмаса да, сөйкемле кызларга хас булган зәңгәр күзләре, алсу йөзе, аз сүзле, көләч йөзле булуы белән гармунчы Галиәсгарнең күңелен яулады. Галиәсгарнең насыйбы Мәгъҗүзә булды. Күңел дигәненә гармун да тәэсир иткәндер. Галиәсгар кыз күңеленә урнашты.

Мәхәббәтләренә киртә булмады. Көзге алмалар өлгергәч, туйлап-туганлашып, Галиәсгар Мәгъҗүзәне үзләренә алып кайтты. Йорт салып, башка чыкты алар. Бер-бер артлы балалары туды. Ләкин гомерләре озын булмады туган балаларының. Мәгьҗүзә балалар хәсрәтен үзенчә уздырды. Иремнән генә аермасын, дип сорады Аллаһтан. Сыналганның сыналасын белдеме, юкмы Мәгьҗүзә... Әллә балалар хәсрәтеннән, әллә нәрсәдән Галиәсгарнең мөнәсәбәте үзгәрде Мәгьҗүзәгә. Ачы телләр, Галиәсгарең Бәдерхәят янына йөри, дисәләр дә, ышанмады. Үзең күрмичә, кеше сүзенә ничек ышанмак кирәк?

Буранлы бер кышкы кичтә, Галиәсгар Бәдерхәят янына җыенганын әйтте. Бу юлы да, сабырын учына җыеп, бөтенләйгә югалту түгел, исән генә булсын, яшәсен генә дип, Галиәсгарнең киемнәрен төенчеккә төйнәде Мәгъҗүзә. Ир бирмәк – җан бирмәк. Галиәсгаргә ачу тотмады ул.

Мәгьҗүзә иренең матур гына яшәвенә сөенде. Күрше-күләннән генә хәл-әхвәлләрен сорашты, исәнлеген белешеп торды. Инде килеп бер көнне йорттагы бердәнбер әтәчне суеп, мунча ягып, чакырып алу уеннан да кире кайтмады Мәгьҗүзә. Күңеле кушканча эшләргә булды. Печән башланганчы дип, Галиәсгар белән Бәдерхәятләргә китте. Галиәсгар Мәгьҗүзәне күрүенә аптырашта булса да, Бәдерхәят ризалашкач, карышмады.

– Яхшы, килербез, – дип җавап бирде.

Токмач куерып кына чыккан иде, Галиәсгар белән Бәдерхәят килеп керде. Мәгъҗүзә кадерле кешеләрен каршы алды. Кунак итте. Мунчага җибәрде. Мунчадан кайткач, коймак белән чәй эчерде.

– Иртәгә иртә белән дә тәмләп чәй эчәрсез! – дип бәлеш төпләрен күчтәнәч итеп төрде.

Әлеге хәл матур гадәткә әйләнде. Ел да Галиәсгар печән алдын көтеп ала башлады. Шулай дәвам иткән булыр иде дә... Ләкин бер буранлы кичтә Галиәсгар Мәгъҗүзә янына кайтып керде. Хатын берни сорашмады. Әйтерсең лә, ире мал-туар яныннан кергән. Иртә таңда самавырлы өстәл өстенә Мәгъҗүзә ике чынаяк куйды, йомырканы да икене түгел, алтыны пешерде.

**Гөлфия Насыйбуллина.**



ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

# “Ата- ананың үзен тәрбияләргә кирәк...”

***Һәр ата-ананың төп бурычы – иманлы, акыллы, киләчәктә үзенә догачы булырдай бала тәрбияләү. Бүгенге буын әти-әниләре әлеге бурычны ни дәрәҗәдә аңлый? Шул хакта Чаллының “Ак мәчет” имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт ШӘЙХЕВӘЛИ белән сөйләшәбез.***

– Әссәламугаләйкум! Рөстәм хәзрәт, килешәсездер, яңа заман татар гаиләсе, әти-әни, бала тәрбияләү өлкәсенә дә үзенең кискен-кискен таләпләрен куйды...

– Әгуузу билләһи минәш-шәйтанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмду лилләһи Раббил гааләмиин, әссаләту үәссәләәму галәә расулиһи Мухәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхәбиһи әҗмәгыйн.

Татар гаиләсе мең еллар буе үзебезгә хас юнәлештә барып, узган гасырның инкыйлабыннан соң кискен үзгәреш алды. Көнбатыштан кергән әхлакый нигезләргә өстенлек биреп, коммунизм тәэзибез дип хыялланып йөргәннәрнең ачысын татыйбыз инде бүген. Россиядә – 82, Татарстанда – 56% гаилә таркала! Ә гаилә ул – дәүләтнең, халыкның, милләтнең бер кырсаткече.

Бүгенге көндә ничектер гаилә, ата-ана, бала өстендәге бурычны исәпкә алмау, яшәп кенә карыйм әле дигән фикер күп кенә гаиләләрнең таркалуына китерә. Элек тә кеше кимчелексез булмаган бит инде югыйсә, әмма аны тотып торган шәригате булган. Үзебезне бүген мөселман дисәк тә, күбебезнең телдән ары китә алганы юк. Кеше бүгенге көндәге дөньясы өчен күбрәк тырыша, баланың киләчәге дигәндә дә ахирәтне уйлау юк, күпләр дөньялыктагы киләчәкне генә кайгырта.

– Элек баланы мәдрәсәгә биргәндә, әти кеше баласын хәзрәт янына: “Ите – сезгә, сөяге – безгә”, – дип алып килгән. Бүген исә мәктәп-мәдрәсәләрдә мөгаллимнең балага катырак тавыш белән дәшәргә дә хокукы калмаган төсле. Баласын яклап, кайбер ата-ана шундый давыл күтәрергә мөмкин! Димәк, гасыр белән гасыр гына түгел, тәрбия чаралары да аерыла?

– Октябрь инкыйлабыннан соң, коммунизм төзүчеләр әзерлибез дип, балалар бакчалары төзегәннәр. Бу – минем фикер. Аннары мәктәп киткән. Аларда – дәүләт тарафыннан үзәкләштерелгән тәрбия үткәрелгән. Ата-ананың кайсы аңлаган аны, кайсы – юк... Кайсы аңлап та әһәмият бирмәгән. Бала тәрбияләү исә шәригать канүннарына нигезләнгән булырга тиеш. Безне халык кылган, кеше итеп яраткан, безгә яшәү рәвешен билгеләгән Аллаһы Тәгалә. Без шул тормыш рәвешен алып барып кына яши алабыз, шуңа нигезләнмәсәк, тормыш итүебез бушка гына китә. “Советлар Союзы вакытында балалар әйбәт иде”, – дибез. Бер нәрсәне онытмыйк: ул чорда дин тоткан әби-бабайларыбыз исән иде! Бөтен бала да хөкүмәт бакчасына йөрмәде бит. Йөргәннәренең дә өйләрендә әби-бабасы бар иде, шул сәбәпле шәригать тәрбиясе күпмедер саклаңып килде. Ул әби-бабайлар үлгәч, дин күрмәгән әти-әниләр калды, берничә елдан алар әби-бабайга әйләнде. Күпчелек халык шәригать күрмәде, шуңа күрә тәрбия чаралары да бүгенге көндә элеккедән бик нык аерыла.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: “Ахырзаман галәмәтләренең берсендә кол хатын үзенә патша тудырыр”, – ди. Чыннан да, бүген балага булган мөнәсәбәт менә шул патшага булган мөнәсәбәт кебек инде. Элек без бәләкәй чакта өстәл янына ашарга җыелганда, иң элек әби-бабай, әти-әни утыра иде. Бүген иң элек баланы утырталар! Кайчак хәттә Корьән мәҗлесенә баргач та карап торасың: анда мулла кайгысы юк, бала көйлиләр. Менә шул хәдискә туры килә торган күренешләр инде болар.

Бүген балага авыр сүз әйтергә, бармак янарга ярамый. Әти-әни балага суга икән, баланы гаиләдән алып, детдомга да бирергә мөмкиннәр. Без үскән чакта матчага кыстырылган чыбык тора иде. Кемгәдер тигәндер ул чыбык, кемгәдер – юк, әмма ул әйбәт тәрбия чарасы булып тора иде. Төрекләр әйтә бит: таяксыз Корьән-хафиз булып булмый, диләр. Пәйгамбәребез дә (с.г.в.): “7 яшьтә баланы намазга бастырыгыз, ун яшьтә дә басмаса, сугыгыз!” – ди. Югыйсә, ул балаларны ничек ярата торган булган!..

– Бүген иң зур проблемаларның берсе – төрле сәбәп белән сыңар канат калган гаиләдә тәрбияләнүче сабыйлар. Ата-ананың аерылышуы үзләрен генә түгел, әле кавырсыны да катмаган балаларны рухи яктан гарипләндерә түгелме? Ул балалар киләчәктә гаилә дигән сүзнең асыл мәгънәсен ничек, нинди үрнәктә аңлар соң?

– Гаилә таркалу иң зур бәлаләрнең берсе булып тора. Гаилә таркала, бала әнисе белән кала. Сугыш вакытында да ятим балалар анасы белән калган, әмма әни кеше баланы герой әтисе белән тәрбияләгән: әтиең булса, шулай итәр иде, болай дияр иде... Ә бүген аерылышалар да, кем гаепле – ата гаепле... Анасы баласына шуны тукый. Бала бераз гаеп эшләсә, шул ук сүз: “атаң сыңары...” Еш кына андый гаиләдә ата кешене бала алдына кире, тискәре бер зат итеп куялар.

Бала гаиләдә дә, бакчада да, мәктәптә дә ир-ат тәрбиясе күрми, кечкенәдән ук хатын-кыз тәрбиясе ала. Мәдрәсәгә килгән шәкертләрдә дә күренә ул. Ире үлеп, баласын ялгыз тәрбияләгән ананы иреннән аерылып бала үстергән хатын-кыз белән чагыштырып карагыз! Беренчесенең баласы сугыш чорындагы әни тәрбиясе алгандай, яхшы әхлаклы булып үсә. Ә аерылган хатын-кызның баласы башка: малайларның да холкы хатын-кызныкы кебек, алар үпкәлиләр, “әнине сагынам” дип кайтып китәләр. Менә бездә ногай малайлары да укыды, аларда ир-егет сыйфатлары ярылып ята. Безнекеләргә карап: “Интересны ваши ребята! Они по маме скучают!” – (килгәндә русча сөйләшсәләр дә, киткәндә рәхәтләнеп татарчага өйрәнеп киттеләр үзләре) дип аптырыйлар иде. Ул ногай малайлары әтиләреннән дер калтырап тора, ә безнең малайларны: “Әниеңә әйтәм!” – дип, әниләре белән куркытабыз. Ә бит бала гаиләдә ир-ат тәрбиясе алырга тиеш! Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: “Атаның балага биргән иң зур бүләге – ул күркәм әдәбе”, – ди. Ягъни ата кеше, турыдан-туры өйдә ятмаса да, гаиләне тәэмин итүче булса да, бала тәрбияләүче булып тора. Ана кеше аны баласына үрнәк итеп күрсәтеп, баланы шулай тәрбияләргә тиеш.

Хатын-кызларның күбесе бүген рыцарьлар юк дип әйтергә ярата. Ул рыцарьларны тәрбияләргә кирәк бит! Без, татарлар, мең еллар буе дөнья белән идарә иткән халык, тегенди-мондый гына халык түгел! Бүген үзебезнең төрки тәрбия чараларыбыз булмый торып, шулар гамәлгә керми торып, өстенлеккә ирешеп булмый. Әгәр әниләр рыцарьлар тәрбияләү үз өсләрендә икәнне аңласа, әтиләр исә үзләрен хатын итәге янында ятучылар түгел, чын рыцарьлар икәнен аңлап, рыцарьларча гамәл кыла башласа, әлбәттә, гаиләдә үзгәрешләр булачак. Тик бүген хатын эшләгәнгә риза булып, өйдә яткан ирләр белән берни эшләп булмый. Беркөн телевизордан сөйлиләр: Татарстанда меңнән артык ир “декретный” алып өйдә утыра, ди. “Декретный”да утырган ул ирләр белән нинди милләт мәсьәләсен хәл итеп булсын?!.. Хатын-кызга да “мин деловой” дип йөрергә кирәк түгел, хатын-кызның аның бөтен “деловой”лыгы – гаиләдә ире тапканны зирәк тотып, бала багып, дөрес тәрбия бирү, сабыр булу.

Сабыр булу дигәннән, тагын телевизордан күргән бер вакыйганы мисал итеп китерәсем килә. Озак еллар бергә яшәгән әби белән бабайны күрсәтәләр, әллә 40, әллә 50 ел торганнар. Торганнар дип, шуның утыз елын бабай төрмәдә уздырган. Кеше үтереп түгел түгелен. “Мин кызу канлы идем”, – дип сөйли бабай. Ул кайтып-китеп йөргән арада 4-5 балалары була, әби үзе өй сала, мунча сала, балаларны үстерә – бабайдан аерылмый. Картайган көнендә бабай да акылга килгәндер – балалары, оныклары матур бер гаилә булып җыелганнар. Менә ул оныклар әби белән бабайның тигез яшәвен күреп, алардан үрнәк алса, (бабайның төрмәдә утыруыннан түгел, әлбәттә), үзләре дә парлы, тигез тормышта яшәячәк бит.

– Бүген һәр ата-ананың йөрәк ишеген ничек кагарга соң?..

– Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: “Ата-ананың бала алдында 3 бурычы бар: бала тугач, матур исем кушу; аңа китап өйрәтү (ягъни, Корьән укырга өйрәтү – ул бөтен тәрбияне үз эченә ала); бәлигатькә ирешкәч, өйләнештерү”. Менә шушыларны аңласын өчен иң башта ата-ананың үзен тәрбияләргә кирәк шул... Үтә торган дөнья белән генә чикләнергә кирәкми. Дөнья үтә ул. Нинди халыклар, империяләр булган! Барысы да беткән, таркалган. Без ахирәткә ни белән барабыз? – Шул хакта уйланырга кирәк.

Дингә күндерүче – Аллаһы Субхәнә Тәгалә. Без турыдан-туры гаилә эшенә катыша алмыйбыз, бездән – дәгъвәт, тырышлык. Тамчы тама-тама таш тишә, ди. Һәрберебез кулдан килгәнчә көч куйсак, иншалла, бер хәерле нәтиҗәгә килми калмабыз...

***Әңгәмәдәш - Айгөл Әхмәтгалиева.***

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Айгөл Абдуллина**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45
* * *
**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.
**Тиражы 1280.**

**Индексы 54149**
* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Корьән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**20 август 16 сәг.**
**фактта 20 август 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**